# ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

**№1** **02 ноябрь 2023 ел**

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Әлкәй авыл җирлеге составына керүче
Әлкәй авылында гражданнар
жыены нәтиҗәләре турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Уставы нигезендә 2023 елның 02 ноябрендә түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гаражданнар җыенының йомгаклау протоколы төзелде:

«Сез, 2024 елда 1 төркем инвалидлар, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, махсус хәрби операциягә юнәлтелгән гаилә әгүзасы тупланган гаиләләрдән тыш, Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Әлкәй авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- Әлкәй авылы территориясен төзекләндерүне оештыру (карны механикалаштырылган җыештыру хезмәтләре өчен түләү, чит оешмаларның юлларны кардан чистарту хезмәтләре);
- территорияне төзекләндерүне оештыру (территорияне механикалаштырылган чаптыру хезмәтләре өчен түләү, шартнамә буенча эшләр өчен түләү, Әлкәй авылы территориясен яшелләндерү чаралары);
-җирлектә яшәүчеләр өчен массакүләм ял итү өчен шартлар тудыру һәм халык күпләп ял итә торган урыннарны төзекләндерүне оештыру (Әлкәй авылында парк төзекләндерү);
-халыкны су белән тәэмин итү (эчә торган су линияләрен һәм колонкаларын ремонтлау);
- Әлкәй авылындагы торак пункт чикләрендәге гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзекләндерү.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия 330 гражданнар җыенында катнашучы теркәлгән, халык җыенында катнашып тавыш биргән гражданнар саны 172.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен 172, «КАРШЫ» » позициясе өчен 0 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Әлкәй торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – гамәлдә (дөрес) дип танырга.
2. Түбәнәге сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга:

«Сез, 2024 елда 1 төркем инвалидлар, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Әлкәй авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- Әлкәй авылы территориясен төзекләндерүне оештыру (карны механикалаштырылган җыештыру хезмәтләре өчен түләү, чит оешмаларның юлларны кардан чистарту хезмәтләре);
- территорияне төзекләндерүне оештыру (территорияне механикалаштырылган чаптыру хезмәтләре өчен түләү, шартнамә буенча эшләр өчен түләү, Әлкәй авылы территориясен яшелләндерү чаралары);
- җирлектә яшәүчеләр өчен массакүләм ял итү өчен шартлар тудыру һәм халык күпләп ял итә торган урыннарны төзекләндерүне оештыру (Әлкәй авылында парк төзекләндерү);

-халыкны су белән тәэмин итү (эчә торган су линияләрен һәм колонкаларын ремонтлау);

- Әлкәй авылындагы торак пункт чикләрендәге гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзекләндерү.

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Әлкәй авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru) хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әлкәй авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Әлкәй авыл җирлеге башлыгы С.З.Зиннурова